РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

28.02. 2019 Чистай шәһәре №32/2

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәр Советының
27.06. 2018 елгы “Ачык тыңлаулар
(җәмәгать тыңлаулары) оештыру
һәм үткәрү тәртибе турында”гы
Нигезләмәне раслау турында”гы
26/2 нче карарына үзгәрешләр
кертү турында

Чистай шәһәр прокурорының “Ачык тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәсенә 30.01. 2019 елгы 02-08-02-2019 нчы протестын карап, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131 нче Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 27.06. 2018 елгы “Ачык тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау турында”гы 26/2 нче карары белән расланган ачык тыңлаулар (җәмәгать тыңлаулары) оештыруһәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбзндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4нче маддәнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Ачык тыңлаулар халык, муниципаль берәмлек Советы (алга таба –Совет), муниципаль берәмлек башлыгы яки үз вәкаләтләрен контракт нигезендә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – башкарма комитет җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.”;

1.2 5нче маддәнең 1нче пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль берәмлек башлыгы яки муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе инициативасы белән уздырыла торган ачык тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.”;

1.3 9нчы маддәнең 2 нче пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җирле бюджет проекты һәм җирле бюджетны үтәү турындагы отчет буенча ачык тыңлаулар муниципаль берәмлек башлыгы карары белән билгеләнә.”;

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук Чистай муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов